**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең Зур Фролово  авылында гражданнар җыены карары**

11 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең  Зур Фролово авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Зур Фролово авыл җирлегенең  Зур Фролово  авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия  балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә

- Зур  Фролово авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Зур Фролово авыл җирлегенең  Зур Фролово  авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Зур Фролово авыл җирлеге башлыгы _________ М.С.Кудряшов

Халык җыены секретаре _________ В.А. Антипова